Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

30 октябрь 2020 ел № 9

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтләренә Бердәм тариф челтәре буенча түләүгә кертелмәгән, Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтләренә түләү шартлары» турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендә аерым оешма хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтләренә Бердәм тариф челтәре буенча түләүгә кертелмәгән, Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтләренә түләү шартлары »турындагы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 7 пунктындагы 6 абзацында «карарлар» сүзен «карар» сүзенә алмаштырырга»;

1.2. карарның 1 нче кушымтасындагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтләренә Бердәм тариф челтәре буенча түләүгә кертелмәгән, Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүче җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфа исеме | Вазыйфа оклады күләме, сумнарда |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә җитәкчесе (бүлек җитәкчесе) | 15 638 |
| Мөстәкыйль идарә җитәкчесе урынбасары | 15 178 |

| | |
|---|---|
| Бүлек башлыгы | 14 603 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 13 913 |
| Баш белгеч | 13 223 |
| Әйдәп баручы белгеч | 12 533 |
| I категорияле белгеч | 11 728 |
| II категорияле белгеч | 11 613 |
| Белгеч | 11 498 |

1.3. карарга 2 нче кушымтаның таблицасында "11 163» санын" 11 498 " санына алмаштырырга;»;

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджетлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

4. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник», газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов